Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының
Кәркәүч авыл җирлеге Советы

# КАРАР

27 февраль 2023 ел №4

Кәркәүч авыл җирлеге Советының 2018 елның 27 апрелендәге 13 номерлы карары белән расланган Кукмара муниципаль районы Кәркәүч авыл җирлеге муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында»2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Кәркәүч авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Кәркәүч авыл җирлеге Советының 2018 елның 27 апрелендәге 13 номерлы карары белән расланган Кукмара муниципаль районы Кәркәүч авыл җирлеге муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә (2018 елның 31 октябрендәге 34 номерлы, 2019 елның 17 маендагы 11 номерлы, 2020 елның 20 мартындагы 8 номерлы, 2021 елның 25 мартындагы 6 номерлы, 2022 елның 15 июнендәге 15 номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 8 бүлекнең 1 пунктына түбәндәге эчтәлектәге 12 пунктчаны өстәргә:

«12) алар тарафыннан чит ил агенты статусын алу.»;

1) 15 бүлекнең 1 пунктына түбәндәге эчтәлектәге 5 пунктчаны өстәргә:

«5) муниципаль хезмәткәр тарафыннан чит ил агенты статусын алу.».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында», Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://kukmor.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кәркәүч авыл җирлеге территориясендәге мәгълүмат стендларында бастырырга.

Җирлек башлыгы М.Ф.Зәйнетдинов